| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ НЫРЬИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>НЫРЬЯ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**КАРАР** **КАРАР**

Нырья авылы

**«19» май, 2023 ел** **№ 9**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Кенә-Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нырья авыл җирлеге Уставы нигезендә, Нырья авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елның 30 маена 11 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Кенә-Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иске Кенә-Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Кенә-Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

2 нче пунктның икенче абзацын тулыландырырга: «юлга вак таш җәю, Иске Кенә-Юмья авылының Мәскәү урамында, баш-башларны ныгытып, су үткәрү торбасын озынайту; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев

ОГРН 1021607753111
ИНН 1623002336